Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
Туктар- Урдаласы авыл җирлеге
Карагай авылында гражданнар җыены
КАРАРЫ

2021 елның 20 ноябре № 3

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Туктар- Урдаласы авыл җирлегенең Карагай авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 20 ноябрендә 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Туктар- Урдаласы авыл җирлеге Карагай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, түбәндәге категория гражданнардан: ялгыз картлар һәм аз керемле гражданнардан, түләүле нигездә белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- Тельман урамында юлга вак таш җәю;
-Карагай авылы юлларын кардан чистарту

«ӘЙЕ» «ЮК».

соравы буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

Халык җыены беркетмәсе нигезендә:
Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 95кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 52 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучылар бертавыштан «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирделәр.
Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Туктар- Урдаласы авыл җирлегенең Карагай авылында гражданнар җыены карар бирде:
1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Туктар- Урдаласы авыл җирлеге составына керүче Карагай авылында гражданнар җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Туктар- Урдаласы авыл җирлеге Карагай авылында территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, түбәндәге категория

гражданнардан: ялгыз картлар һәм аз керемле гражданнардан, түләүле нигездә белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Тельман урамында юлга вак таш җәю;
- Карагай авылы юлларын кардан чистарту

соравы буенча карарны кабул ителгән, дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Туктар-Урдаласы авылы, Совет ур., 98 адресы буенча урнашкан административ бинада, Совет ур., 103 йорт, Карагай авылы, Тельман ур., 31 йорт адресы буенча урнашкан КФҮ бинасында урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Туктар- Урдаласы авыл җирлеге башлыгы Г.Ә.Әхмәтова